**Аннотация к рабочей программе воспитателя по обучению детей татарскому и родному языкам**
**МБДОУ комбинированного вида «Красногорский детский сад «Радуга» Мамадышского муниципального района Республики Татарстан**
**Саляховой Гульнур Мубаракзяновны**

"Татарстан Республикасы халыклары телләре турында" Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган.

"Балалар бакчасында рус һәм башка милләт балаларын татарча аралашырга һәм татар балаларын ана теленә өйрәтү" программасы (алга таба программа) алда күрсәтелгән чыганакларга нигезләнеп төзелде.

Программа 2 яшьтән 7 яшькә кадәр булган татар балаларын ана теле, 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларны татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен үз эченә ала. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л. С. Выготский, В. В. Давыдов, Е. И. Пассов, П. Я. Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

**Программаның максаты һәм бурычлары.**

"Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү" программасына нигезләнеп, "Татарча сөйләшәбез" укыту-методик комплекты 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларны 167 сүз кысаларында татарча аралашырга өйрәтүне үз эченә ала. Шуннан чыгып, эш программасына түбәндәге максат, бурычлар билгеләнде.

Максат: Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны 167 сүз кысасында, уен технологияләре кулланып, татарча аралашырга өйрәтү.

Бурычлар:

1.Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2.Предметларны, аларның билгеләрен һәм хәрәкәтне белдерүче сүзләрне сөйләмдә активлаштыру.
3.Көндәлек яшәеш ситуацияләреннән чыгып диалоглар төзү.

"Туган телдә сөйләшәбез" укыту-методик комплекты балалар бакчасында беренче кече яшьтәге, икенче кече яшьтәгеләр, уртанчылар, зурлар, мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә татар балалары белән эшләү өчен тәкъдим ителә. Шуннан чыгып, татар төркемнәрендә тәрбияләнүче балаларга ана телен өйрәтү өчен эш программасына түбәндәге максат, бурычлар билгеләнде.

Максат: Балаларны, уен технологияләре кулланып, ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү.

Бурычлар:

1. Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру.
2. Бәйләнешле сөйләмне мөстәкыйль фикер йөртү нәтиҗәсе буларак үстерү.
3. Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Заведующий МБДОУ
«Красногорский детский сад «Радуга» ____________ Мартынова Н.Г./